КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 август г.Казань № 928

2023 елда алына торган торак урыннары өчен милекчеләргә түләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2023 елда алына торган торак урыннары өчен милекчеләргә түләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 1 август, 928 нче
карары белән расланды

2023 елда алына торган торак урыннары өчен милекчеләргә түләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетына Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Радужная урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләрен Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 10 өлеше нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен алуга бәйле рәвештә милекчеләргә алына торган торак урыннары өчен түләү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү (алга таба - тиешенчә башка бюджетара трансфертлар, алына торган торак урыннары) механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар 2023 елда бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирүгә бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

5. Азнакай муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

Азнакай муниципаль районының милекчеләргә алына торган торак урыннары өчен акча түләүне башкару турында хокукый акты булу;

Азнакай муниципаль районы бюджетында (Азнакай муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасында) милекчеләргә алына торган торак урыннары өчен акча түләүне башкару буенча Азнакай муниципаль районы чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

Министрлык белән башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба - килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе - Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә милекчеләргә алына торган торак урыннары өчен тулы күләмдә акча түләү.

7. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен Азнакай муниципаль районы ирле үзидарәсенең вәкаләтле органы Министрлыкка башка бюджетара трансфертларны ирекле рәвештә бирү өчен заявка бирә.

8. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Азнакай муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы арасында төзелә торган бертип форма буенча килешү нигезендә эш

көннәрендә санала торган 10 көн эчендә ирекле рәвештә башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гариза кергән көннән алып бирелә.

9. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибе һәм сроклары;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын Азнакай муниципаль районы тарафыннан үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең килешү белән билгеләнгән һәм фактта ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә Азнакай муниципаль районның финанс органына ачылган Азнакай муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

12. Азнакай муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы 2024 елның 1 гыйнварына кадәр Министрлыкка финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенә ирешү хакында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушып бирелә торган рәвешләр буенча хисаплар тапшыра.

13. Азнакай муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

14. Бу Тәртип нигезендә алынган, 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бу Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемнә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми

таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә акча әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә агымдагы финанс елында әлеге башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына туры килә торган Азнакай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен алар элегрәк бирелгән Азнакай муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

15. Башка бюджетара трансфертлар һәм (яисә) Азнакай муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы аларны бирү шартларын максатчан файдаланмаган очракта, шул исәптән Азнакай муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан әлеге Тәртипнең 14 һәм 16 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчалар кермәгән очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

16. Азнакай муниципаль районы тарафыннан килешүдә билгеләнгән вакытларда башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, Азнакай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{\text{кире кайтару}} = V_{\text{мбт}} \times k,$$

монда:

$V_{\text{мбт}}$ – Азнакай муниципаль районы бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

Азнакай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләп чыгарганда хисап финанс елында Азнакай муниципаль районы бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә ($V_{\text{мбт}}$) 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше исәпкә алынмый.

Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S - килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең план күрсәткече.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Азнакай муниципаль районы тарафыннан башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.